| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**ГЛАВА**<br>**БОЛЬШЕШЕМЯКИНСКОГО**<br>**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**<br>**ТЕТЮШСКОГО**<br>**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**ТӘТЕШ**<br>**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**<br>**ОЛЫ ШӘМӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**<br>**БАШЛЫГЫ** |

тел. (84373) 56-6-48, факс 56-6-48

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**21 август, 2020 ел** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Шәмәк авыл җирлегенең Олы Шәмәк торак пунктында, гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча, гражданнар җыенын билгеләү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәләр оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56, 25.1 маддәләре, “Татарстан Республиксында җирле үзидарәләр турында”гы 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы “Олы Шәмәк авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 23 маддәсе нигезендә **КАРАР КЫЛАМ:**

1. 2020 елның 2 сентябрендә 14 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Шәмәк авыл җирлегенең Олы Шәмәк торак пунктында түбәндәге адрес буенча урнашкан Олы Шәмәк авылы мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Олы Шәмәк авылы, Пролетарская урамы, 10 нчы А йорт.

2. Гражданнар җыенында тәкъдим ителүче мәсьәләне раслау:

“Сез, 2020 елга җыелган 158640 (йөз илле сигез мең алты йөз кырык) сум күләмендәге гражданнарның үзара салым акчаларын “Олы Шәмәк авылының Мәктәп, Пролетарская, Ленин, Кутузов, Совет урамнарындагы юлларны ремонтлау”дан “Олы Шәмәк авылының Пролетарская урамында урнашкан авыл үзәген төзекләндерү”гә күчерергә ризамы?

«РИЗЫ» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Шәмәк авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрү йөкләнелә.

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы”нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырып халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар басылган көненнән башлап үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Олы Шәмәк авыл җирлеге**
**Башлыгы** **А.И. Афанасьев**